ГЛАВА ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.11.2025 г. Заинск №174

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башлыгының 2017 елның 24 ноябрендәге 243 номерлы "Зәй муниципаль районы Советында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибен раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 10 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 40 статьясына таянып

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башлыгының 2017 елның 24 ноябрендәге 243 номерлы «Зәй муниципаль районы Советында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе турында» карарына (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башлыгының 2018 елның 14 февралендәге 37 номерлы, 2021 елның 20 декабрендәге 192 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 нче пунктта:

а) 2 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданның язма рәвештә бәян ителгән мөрәҗәгатендә мөрәҗәгать җибәрелә торган органның исеме, йә тиешле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, йә тиешле затның вазыйфасы, шулай ук тәкъдимнең, гаризаның яисә

шикаятьнең асылын бәян итү, гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), җавап, мөрәҗәгатьне башка адреска юллау турындагы хәбәр җибәрелергә тиешле почта адресы, аның шәхси имзасы һәм дата булырга тиеш.»;

б) 3 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Органга яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгать законнарда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан мәҗбүри тәртиптә үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта) күрсәтә, шулай ук электрон почта адресын күрсәтә яки шәхси кабинетының адресын (уникаль идентификаторын) "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы" (алга таба - Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасында яисә җаваплар җибәрелергә тиешле гражданның идентификациясен һәм (яисә) аутентификациясен тәэмин итә торган дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының (алга таба - башка мәгълүмати система) башка мәгълүмат системасына мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәрнамә җибәрелергә тиеш. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон рәвештә теркәргә яки күрсәтелгән документларны һәм материалларны яисә аларның күчермәләрен язма рәвештә җибәрергә хокуклы.»;

1.2. 2.3 нче пунктның беренче абзацында «Барлык язма мөрәҗәгатьләр Зәй муниципаль районы Советына кергәннән соң өч көн эчендә теркәлә» сүзләрен «Зәй муниципаль районы Советына керә торган барлык мөрәҗәгатьләр Федераль законда һәм Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә теркәлә. Әгәр гражданның мөрәҗәгате эш көне тәмамланганнан соң яисә ял көнендә кергән булса, ул икенче эш көненә теркәлергә тиеш. Шул ук вакытта мөрәҗәгатьне карау өчен билгеләнгән срок фактта кергән көннән түгел, ә ял көненнән яисә эш көне булмаган бәйрәм көненнән соң беренче эш көнендә рәсми теркәлгән вакыттан башлана» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының гомуми бүлеге башлыгына йөкләргә.

**Муниципаль район Башлыгы** **Р.К. Кәримов**